16+ ФАЙДАЛЫ КИҢӘШЛӘР, ЧЕТЕРЕКЛЕ һӘМ КАРШЫЛЫКЛЫ ЯЗМЫШЛАР – БЕР ГАЗЕТАДА

# Ясминә

№8(104) октябрь, 2024 ел

ИНДЕКС П2250















## СИНЕ УЙЛАП СЫЗЫЛАМ

***Ир-атның чәчләре агара башласа, күңеленә шайтан керә диләр. Менә Хөснулла да әлегә кадәр хатынына тугры ир, балаларына яхшы ата булды. Таныш-белешләре, иптәшләре арасында абруйлы, холык-фигыле үрнәк иде. Район үзәгендә урнашкан агач эшкәртү оешмасында кырык ел җиһаз ясады ул. 65кә кадәр эшләде. 65е тулгач, хөрмәтле ветеранны зурлап пенсиягә озаттылар. Бүләккә ярты өстәл кадәр телевизор бирделәр.***

Хатыны Мәйсәрә пенсиягә ике ел элек чыкты. Хәзер әби белән бабайга үзләрен тәрбияләп, сәламәтлекләрен кайгыртып, тыныч кына яшәргә инде.

Хөснулла айга якын яңа тормышка күнегергә тырышып карады. Совет заманнарында аңа эшеннән ике катлы йорттан фатир биргәннәр иде. Янында, кечкенә булса да, бакчасы бар. Үзәктән читтә булгач, фатирны юк кына бәягә сатып, кирпеч йортка күченде Хөснулла. Бар уңайлылыклары булган өйдә, сүз дә юк, күпкә җиңелрәк иде. Бүген килеп, ир иске фати-

podpiska.pochta.ru

рын сатуына үкенеп тә куйды. Үз җаена бакчасында җиләк-җимеш, яшелчә үстереп ятар иде.

Ямансулап шулай йөрдейөрде дә, авыл хуҗалыгы техникумына эшкә урнашып кайтты. Шул уку йорты тирәсен себергәләп, вак-төяк ремонт ясап, укучыларга күз-колак булып йөрергә тиеш булды ул. Тик Мәйсәрә иренең бу чыгышын өнәмәде. Телевизор карап, газит укып, пешергәнне ашап өйдә ятса, ни була? Үзләренә тиешлесен эшләделәр бит инде алар. Ләкин Хәснулла үз сүзендә нык торды. Аңа шөгыль, хәрәкәт кирәк иде. Кузгалмый ятсаң, буының таш булып катар!

Хәснулланың вазифасы авыр түгел. Ул кушылганнарны күңел биреп башкарды. Күңел дигәннән, бу яңа эш урыны аның күңелен урыныннан кузгатты. Элекке эшендә Хәснулла гел үз ишләре арасында иде, ә монда хатын-кызлар янына килеп эләкте. Җыештыручылар, пешекчеләр, кизү торучылар – барысы да хатын-кызлар. Бөтен җирдә чисталык, тирәякта агач тузаннары да очмый. Тәрәзә төпләрендә аллыгөлле чәчәкләр, хатыннарның үзләреннән дә хушбуй исләре генә килеп тора. Хәснулла башта югалыбрак та калды. Аннан ияләнеп китте. Аны чәй эчәргә чакырдылар, киңәшләр сораган булдылар, берәр эштә ир кулы кирәк булып, ярдәм итүен үтенделәр. Кыскасы, тирәсендә бөтерелеп, сандугач булып сайрадылар. Аларның назлы тавышлары, серле карашлары ирнең күңелен эретте. Тирәяк дөнья икенчерәк төсләрдә күренә башлады. Ул да әлегә кадәр яшим дип йөргән икән. Бар белгәне такта-брус булды, шуннан артыгын күрмәде. Арыпталып эштән кайткач, күзенә Мәйсәрәсе фәрештә булып күренә иде. Күп икән лә андый гүзәл затлар. Картлык чорына кергән җәмәгате телгә беткән бу хатыннарга күпкә оттыра.

Хәснулла эчтән генә үзен нәфескә буйсынмаска, аек акыл белән фикер йөртергә чакырса да, яңа хис-тойгыларга көннәнкөн тартыла барды. Бу хатыннар арасыннан Алевтинаны күңеленә аеруча якын итте. Гел елмаеп торган, кырыкны чак узган чибәр чуваш хатыны иратны абындырырлык көчкә ия иде шул.

Гардеробта эшләгән Алевтина янына Хәснулла кырык сәбәп табып керә торган булды. Хатын-кызларның игътибар иткәнне яратканын ишеткәне бар иде. Ә бу игътибар бүләкләтә булса, аларның күңеленә бигрәк тә ошый икән. Шуны истә тотып, Хәснулла бер дә буш кул белән кермәде. Тол хатынның алдына йә бер кап прәннек, йә уч тутырып кәнфит салды. Шундый үзенчәлеге бар адәм баласының: аңа юраганы юш килгән төсле тоела башлый. Хәснуллага да хатын аңа битараф түгел кебек тоелды. Ул күңеленнән әллә ниләр күзаллый башлады. Имеш тә, уйнаклап торган Алевтина белән аулакта очрашканнар, учына тегенең йомшак кулларын алган... Күп инде ул хыяллар, барысын сөйләп бетереп кенә булмый.

Мәйсәрә дә ирендә ниндидер үзгәрешләр барганын тоемлады. Хатын-кыз күңеле сизгер бит ул. Никахлы ире ничектер эреләнеп киткәндәй тоелды, килеш-торышларыннан җитешсезлекләр тапты, пешергән ашларын ошатмады. Кайгыга калган хатын моны ни-нәрсәгә юрарга белмәде. Ә Алевтина картлык чорына кергән Хәснулланың кыланмышларын шаяру итеп кабул итте. Күңелен ачкан иргә каты бәрелмәде, "зыяны тими ич" дигән тәстәрәк йөри бирде. "Киртәдән сикерә башласа", ул бу картны урынына утыртырга да күп сорап тормас.

Иренең көйсезләнеп йөргәннәре турында баш вата торгач, Мәйсәрә моның тамыры яңа эш урыныннандыр дигән төпле фикергә килде. Район җирендә халык бер-берсен күреп белә, хатын-кызлар барысы турында да аеруча хәбәрдәр. Техникумда җыештыручы булып эшләгән Гамбәрия исемле хатын – Мәйсәрәнең якын гына танышы иде. Ул Гамбәрия аркылы бу хәлләрнең серен белергә уйлады.

Бу вакытта Хәснулла хыялында йөрткән ләззәтле уйларны тормышка ашырырга вакыттыр дигән фикергә килгән иде. Вакытын туры китереп, кеше-кара күрмәгәндә хатынга сүз кушты:

– Сине уйлап сызылам, Алевтина. Йокым йокы, ашаган ашларым аш түгел. Ут якның йөрәгемә. Аулакта очрашып сөйләшик әле бер, – дип тәкъдим ясады.

Алевтина, барысын да уенга борып, тизрәк аның яныннан китуягын карады.

Мәйсәрә теге танышыннан сораштыра торгач, иренең бер чуваш хатынына күзе төшкәнен белеп алды. Ул Алевтинаны таный иде. Кибеттән чыкканын туры китереп, сүз кушты. Хәснулла исемен ишеткәч, тегесе:

– Чистый сагыз булды! Тагын шундый сүзләр сөйләсә, кеше алдында хур итәм мин аны. Уема да кереп чыккан кеше түгел ирең! – дип ярып салды.

Әммә Мәйсәрә акыллы хатын, аңа башка төрле киңәш бирде.

Хәснулла тагын Алевтинага очрашу турында сүз катты. Ни гаҗәп, бу юлы хатын каршы килмәде, иртәгә эштән соң аны фатирында көтәчәген әйтте. Шатлыгыннан авызын җыеп ала алмаган ир чак таң аттырды, аның өчен эш көне дә озак үтте. Ниһаять, эше тәгәлләнде. Техникум капкасыннан чыккач, туп-туры кибеткә китте. Акчасын җәлләми барысын җыйды: кыйммәтле колбасалар, сыр, кәнфит, чәк-чәк. Хакыннан тормады, арага грузин коньягы да кыстырды. Алевтина белән ара-каршы утырып бәйрәм итәчәкләрен күзаллап, урам буйлап шәп-шәп атлады. Икенче катка күтәрелгәч, ишек кыңгыравына басты. Ачык икән, Алевтинаның тавышы ишетелде:

– Кер, кер, мин хәзер әзер булам...

Дулкынланган Хәснулла аяк киемнәрен салып эчкә үтте һәм йөрәге тукталып калгандай булды. Зур якта, өстәл артында, кукраеп Мәйсәрә утыра иде. Хәснулланың кулындагы пакеты төшеп китте, аяге асылынды.

– Монда нишләп йөрисең, карткынам? Мин менә дус хатынымның хәлен белешергә кергән идем! – диде Мәйсәрә, аңа каршы чыгып.

Хәснулла ничек аягына киеп, ни рәвешле чыгып киткәнен дә хәтерләмәде. Мәйсәрә, теге күчтәнәчләр белән чәйләр эчеп, соң гына кайтты.

– Чәй дә эчеп тормадың безнең белән! – дип төрттереп тә алды әле ул.

Икенче көнне үк Хәснулла эшеннән китте. Бер гаражга машина сакларга барып керде. Монда, ичмасам, җаны тыныч: күңелне кытыкларга хатыннар юк. Ә теге көн турында акыллы Мәйсәрә бүтән сүз чыгармады. Нәрсәсен кабатлап торасың: аның моңа кадәр тугры булган ирен шайтан гына котыртып алды бит.

**Һ.КӘРИМОВ.**



***Исәннәрмесез, кызлар! Бераз авылыбыз хәлләрен сөйләп, шатлыклар белән уртаклашасы килеп шалтыратуым иде. Өлкәннәр көне булды бит. Ул көн узып киткәч, бөтен пенсионер да шуны сөйләшә бит инде. Күрше авыллар, күрше районнарда яшәүче әби-бабайларның да телендә шул гына. Кемнәрнең телефоны бар, күчтәнәчләрне фотога төшереп, бер-берсенә дә җибәрәләр. “Сездә ничек? Бездә шулай булды”, – дип бер кат сөйләшеп алабыз. Арада төрле җирлекләр бардыр инде. Кайда ничектер хөрмәт.***



# Сездә ничек?

Безнең Кәкре Елгада бәйрәм бик матур узды. Быел гына түгел, бездә ел да бик мулдан уздыралар аны. Авылда бик матур ашханәбез бар. Колхоз председате, авыл советы председателе, авылдан чыккан хөрмәтле кешеләр дә кайта. Шуның кадәр күңелләр булып кайттык инде, белсәгез. Хәзер менә ничә көн үтте инде, ә һаман шуның тәэсирендә йөрибез әле. Табыннарда буш урын юк иде, җитәкчеләребез шундый матур сүзләр әйтеп котладылар. Өстәлләр дә бик мул иде, әкәмәт. Аш та бар, ботка да бар, итләре дә күп иде, 2-3 төрле салатлары да, шифалы сулары да бар иде, кызлар пирогларын да пешергәннәр иде. Ашап-эчеп, концерт карап, сөйләшеп, аралашып, күңел ачып кайттык.

Укытучыларны да котладык, аларның да бәйрәме булды бит. Алла ярдәм бирсен дим инде. Мин, мәсәлән, үзем гомердә дә укытучы булып эшли алмас идем.

Минем алдан да әйткәнем бар иде инде, без бик рәхәт яшибез авылыбызда. Бәйрәм уңаеннан гына түгел, гомумән алганда рәхәт безнең монда. Әле тагын шунысын да әйтим, бездә, мәсәлән, 70 яше тулган һәр кешегә колхоз бишәр кило песок та бирә. Мин үзем әлегә ул яшьтә түгел. Җырдагыча әле минем: яшьлек үтмәгән, картлык җитмәгән дигәндәй. Әмма шундый котлауның булуы үзе үк күңелле бит инде. Кайда бар әле ул менә шулай зурлап котлаулар, әйме?

Тиздән менә авылыбыз мәчетендә укулар башланырга тора, теләгән кеше шунда йөри ала. Мин үзем монда килен булып төшкән кеше генә, алай да, авылны бик яратам. Гомерем шушында үтте. Кешеләрен дә яратам, авылны да яратам. Кая гына барсам да, куанып кайтам. Шундый рәхәт һәм шундый чиста безнең монда. Кышлар җитсә, юлларыбыз ачык тора безнең, суларыбыз әйбәт килә.

Әле менә бәрәңгеләрне алып бетердек. Тулаем алганда, начар булмады бугай. Елына күрә ярый. Арасында төрлесе бар инде, кешеләр дә төрлечә сөйлиләр. Алай да, хәзергә ашарга җитеп торыр әле дип уйлыйм. Кабаклар күп булды, чөгендер күп булды. Колхозда уборка эше бара хәзер менә: көнбагыш күп, рапс чәчкәннәр иде. Бер пай җиренә ике рулон вика үләне бирделәр, әле икмәк тә бирәбез диделәр. Шатлыклы хәбәрләр бит инде, авыл кешесе шушындый көндәлек мәшәкатьләр, көндәлек шатлыклар белән яши. Әзрәк шөкерана да әйтә белергә кирәк дим инде мин. Гел бертуктаусыз моңаеп утырып та булмый, зарланып кына да яшәргә кирәкми инде ул хәтле. Ач утырмыйбыз, кияр киемебез бар. Безгә, пенсионерга, тагын нәрсә кирәк инде менә, әйме? Рәхәтләнеп яшәрлек кенә. Пенсиябез килеп тора, почтабыз эшләп тора. Мин ул почтадагы кызларны да мактап кына торам. Бәй, ничек мактамыйсың әйбәт эшләгән кешене?! Мактарга кирәк! Мин шулай дип уйлыйм.

Газеталарыгызны бик яратып укыйбыз, кызлар, көтеп кенә торабыз, кулдан-кулга йөртеп, алмашлап укып барабыз. Бездә аны яшьләр дә укый, олылар гына түгел. Алга таба да безне куандырып эшләп торыгыз, яме. Минем телевизорга исем китми, мәсәлән. Миңа укырга кирәк, газета булсын, китап булсын.

Язмам чыкса, тагын язгансың дип әйтерләр инде. Ара-тирә минем шулай язганны белеп торалар бит. Андый чакта әйтәм инде, әйе, язам шул, әйбәт кенә булыгыз, дип көлдерәм.

Исән-сау булыйк, кызлар! Мин шулай шалтыраткалап торырга тырышырмын әле сезгә.

**Азнакай районы Кәкре Елга авылыннан Сания апагыз МӨХӘММӘТҖАНОВА.**

# Укыгыз! Яздырыгыз!

Газеталарыгызны бик яратам инде, үлә язып укыйм, көтеп ала алмыйм. Бик әйбәтләр шул! Әллә ничә кешегә әйттем инде, укыгыз, яздырыгыз, дидем. Стәрледәге танышларга да әйттем, яздырыгыз, шулхәтле әйбәт газеталар бит, дидем. Бөтен киңәшләрне шуннан алып була. Файдалы киңәшләрне алып, тегеп куям әле мин. Озын-озак итеп эшләгез, кызлар.

**ЗӨЛФИРӘ, Стәрлетамак районы Талач авылы.**




# Хатлар яздым утырып

Исәнмесез, хөрмәтле “Ясминә” кызлары! Сезгә Ленинград өлкәсеннән Әнәс бабай хат яза. Сезнең газетаны туганнарыма ялга кайткач күрдем. Беренче битеннән соңгы битенә кадәр кабат-кабат укыдым, шуның кадәр ошады. Газетагызда укучылар сораган җырларның сүзләрен бастырасыз икән. Минем дә бер җырның сүзләрен табасым килә. Заманында ул җырны Гөлсем апа Сөләйманова җырлый иде. Истә калган сүзләре менә болай:

*Сания апа суга бара,*
*Көянтәсе алмалы.*
*Алмалы көянтәсенә*
*Кунмаган кош калмады.*

**Әнәс бабай НУРИЕВ,**
**Ленинград өлкәсе Ломоносовский районы Санино авылы.**

## САНИЯ АПА

**Татар халык җыры**

*Сания апа суга бара,*
*Яшел чиләген асып.*
*Сандугачлар чут-чут сайрый,*
*Көянтәсенә басып.*

*Сания апа суга бара,*
*Көянтәсе алмалы.*
*Алмалы көянтәсенә*
*Кунмаган кош калмады.*

*Сания апа суга бара,*
*Алма-алма чиләге.*
*Чиләгенә караганда,*
*Үзе кура җиләге.*

*Сания апа, чиләгеңнән*
*Суларың түгелмәсен;*
*Башкалар сүзенә карап,*
*Күңелең сүрелмәсен.*

*Кая бардың, Сания апа,*
*Кайдан кайтып киләсең?*
*Киләсең дә, гел китәсең,*
*Бик ямансу итәсең.*

# КҮЧТӘНӘЧ

***Саран ирләр турында күп укыганым бар. Андыйлар тормышта да очрап торалар. Әллә дөньясы шундый, ирләр вакчылга әйләнде. Минем ирем андый түгел иде. Ни алсам да, ни кисәм дә, сүз әйтмәде. Ирем үлгәнгә байтак еллар инде хәзер. Балалар да чыгып киттеләр. Берүзем дөнья көтәм. Ирле кешеләр белән йөрешергә туры килә. Туганнарымның да ирләре бар. Апамныкын әйтеп китим әле менә. Хатынына гомер буена акча тоттырмады. Хәзер пенсиясен дә үзенә генә тота. Кайчак түләүләргә бераз бирә бугай.***

Иптәш хатыннар: “Гомер буе ялгыз яшәмәссең, таныш. Бармасаң да, аралашырсыз”, – дип, бер кеше таптылар. Яше 65ләр тирәсендә, өйләнеп аерылган.

Фәрит миңа баштан ук ошамады. Танышкач, бераз төс-бит тә кирәк бит әле ул. Ә бу тәмам бетәшкән бабайга тарткан иде. Ике-өч килде, өстендә – һаман бер үк киемнәр. Хатын-кыз янына килгәндә, төрләндереп барырга кирәк.

Бер килгәндә, кулында очсыз гына кәнфит бар иде. Мин ул көнне бәлеш пешердем, чәй куйдым. Аннан: "Бакчаңда эшләрең бар икән, булышам", – дип тагын бер килде. Өстәлгә бер кап сок, батон, балык куйды. Мин пилмән салдым, пирожки да пешергән идем. Бакчага чыкканда, пакетын кая куярга белмичә аптырады. Карасам, пакет төбендә йөз граммлап сыры бар икән. Чәй эчәм дип өйгә кереп киткәч, аны кесәсенә тыгып куйган. Мин дә төшеп калган түгел бит: курткасын юри капшап карадым.

Ярдәм итәм дип килсә дә, бик куандырмады алай. Бер-ике агач төбен чистартты да, барып утырды. Кергәч, тагын табын көйләдем моңа. "И-и, моның кадәр әзерләнәсеңне белсәм, күчтәнәч алып килмәгән булыр идем", – дигәч, шаклар каттым. Әле ярый килгән өчен бензинга акча сорамады. Яки шул алып килгән күчтәнәчләренең хакын сорамады. Анысыннан ничектер тыелып калгандыр инде, әйтергә бик теле кычыткандыр.

Шул китүдән бер-ике тапкыр шалтыратты бу. Бик җәелеп сөйләшмәдем инде. Мондый саран ник кирәк соң әле дип, хәзер телефонны алмыйм да. Хатыннар, шул дәрәҗәдә саран ирләр күргәнегез бармы сезнең? Дөньяның кеме генә юк, әстәгыймә.

**Минзәләдән.**

✔ Саранның яраткан ашы – күрше шурпасы.
✔ Комсызның карыны туяр, күзе туймас.
✔ Еланның аягын күрмәссең, саранның сыен күрмәссең.
✔ Кешегә көнең төшмәсен, саранга эшең төшмәсен.
✔ Комсыз, абынып егылса да, бер әйбер учлап алмыйча тормас.

**Татар халык мәкальләре.**



# Язмышлар шундый

***Мине әтинең әнисе үстерде. Аерылышкач, әни башкага китеп барды, әти дә үз юлы белән китте. Әби мине беркайчан да әнигә каршы котыртмады. "Кызым, әни – әни булыр, ике артка этсә дә, бер алга, үзенә таба тартыр", – дип әйтә торган иде. Мине менә шулай итеп үстерде ул. Бармыйсың, йөрмә анда дип әйткәне булмады.***



Әни күрше авылда гына яшәде. Җәй көне әби мине күчтәнәчләр белән әни янына җибәрә иде. Авылда нинди күчтәнәч инде: сөт, катык аласың, ипи, йомырка төреп тыга иде әби мәрхүм. "Әниең өйдә булса гына анда кун, өйдә булмаса, абыеңнарда кун", – дип әйтеп җибәрә иде.

Ул авылда безгә туган тиешле абыйлар да яши иде. Әби үги этиләрнең дә төрлеләре турында ишетеп белгәндер инде, мине гел шулай саклап, өйрәтеп үстерде. Ул чакта да төрле хәлләрне ишеттерәләр иде бит инде авыл җирләрендә.

Миңа 17 яшь вакытта әби мәңгелеккә китеп барды. Әбине җирләгәч, әни килеп китте. "Кызым, нәрсә эшләрсең инде хәзер, ни булыр?" – дип сорады да, китеп барды аннары. Мин дә аның белән китмәдем. Берүзем яшәдем, маллар асрап, бәрәңгеләр утыртып тордым. Шуннан соң, күпмедер вакыттан, әти яклап туган абый ерак Комидан кайтты. "Әйдә, алып китәм, урнашырсың, эшләрсең", – дип кыстады. “Юк, бармыйм, мин сагыначакмын”, – дидем. "Кемне сагынасың, нәрсә бар сиңа монда хәзер?" – дип бик озак үгетләде әле ул мине. Авылда берүзе калмасын, китеп урнашсын, акчасы булсын дип уйлагандыр инде үзенчә.

Аларның уйлары изге булса да, мин ризалашмадым. Әйттем инде, җиңги белән сез нәрсәгә булса ачуланышырсыз да, ә мин үземне гаепле кебек хис итәрмен, дидем. “Бармыйм, нәрсә булса, шул булыр”, – дип калдым.

Укырга киттем, гомер буе шәһәрдә яшәдем, эшләдем, кияүгә чыктым, балалар үстердем. Беркайчан эшсез тормадым! Чит җирләргә китмәгәнгә беркайчан да үкенмәдем. Абый белән җиңгә өстенә барып кереп, кем белгән иде анда нәрсә буласын.

Әнинең икенче ирдән дүрт баласы туды. Алар белән хәзер дә аралашып яшибез, әйбәт мөнәсәбәттә торабыз, кунакларга йөрешәбез. Әни 79 яшендә үлде. Мин эшкә урнашкач та гел әнигә кайтып йөрдем, күчтәнәчләр ала идем. Аны хәзер дә искә алалар, ашларга баргач, әни: "Менә, бу күлмәкне Нуриям алып кайтты, матурмы?" – дип мактанып әйтә торган булган.

Ничек кенә булмасын, әнине гаепләп, үпкәләп искә алмыйм. Димәк, язмышлар шундый булган. Көрешеп яшәдек, мине какмады, сукмады, “әни” дип әйтерлек кешем булды. Ул вакытта тормышлар да авыр иде бит. Гел беркемсез, ятим бала булмадым. Әни дә булды, өйдә әби канаты астында үстем, әбидән соң “әйдә, киттек” дигән туганнарым да булды. Тормышлар берәүнеке дә тигез генә бармый. Иң мөһиме, югалып калмаганмын, үсмер көе берүзем авыл тормышы белән яшәгәнмен, кешеләргә ачу тотмыйча үскәнмен. Уйлап карасаң, болар бар да әби белән әни тәрбиясе бит инде. Шулай булгач, нинди үпкә булырга мөмкин?

**НУРИЯ апагыз.**

# ЕГЫЛГАНЫМНЫ КӨТӘЛӘРМЕ...

***Ярармы, юкмы – үземнең төшемне сөйлим әле, кызлар. Мин гомер-гомергә төшләрне бик күп күрәм. Йокларга ятканда: "Апагыз кино карарга китте", – дип өйдәгеләрне көлдерәм дә әле. Кайсыларын юрыйм төшләремнең, ә кайсыларын ничек итеп тә юрарга белмим.***

Төшләремдә су бик күп минем. Нәрсә генә күрсәм дә, гел су белән бәйле була ул, шуңа нык аптырыйм инде. Менә бүген дә шундыйрак бер төш күреп уяндым. Тагын су!

Имеш тә, бианай йортында икәнмен. Краннан туп-туры идәнгә су агып тора. Гади генә йорт ул, агач идәннәр иде аларның. Бәлки хәзер үзгәреп беткәндер инде, анысын белмим. Мин алардан киттем. Төштә, имеш тә, шунда икәнмен. Идәнгә агып торган суны күреп, бик аптырадым инде. Су такталар арасыннан гына идән астына агып кереп китә. Өйдәгеләр белән тиз генә берничә идәнне ачтык. Карасак – идән асты тулы су! Кран суы тутырган. Әле шунда үзем төшеп китә яздым! Аягым таеп китте, ә янымда басып торган берсе дә кул бирмәде. Бианай да карап тора, биатай да. Чүттән генә төшеп китмичә калдым!

Менә шундый төш. Аерылышканнан бирле берсе белән аралашканым да, күрешкәнем дә, искә алып уйлаганым да юк иде. Каян шулай суга батып килеп кергәннәрдер, ни дип уйларга да белмим. Малайларын ташлап киткәнгә ачуланып, төпкә төшеп егылганымны көтәләрме...

**ГӨЛНАРА Б., Мамадыш.**

**Миңа 68 яшь, хатыным белән аерылыштык. Беренче хатыным белән унбиш еллап яшәп аерылыштык, анда уртак балалар булмады. Аннан соң икенче хатынга өйләндем. Анысы белән егерме ел яшәгәч аерылыштык, бер балабыз бар. Аерылышканга ярты еллап кына әле.**

# Әйбәт хатын кирәк

Миңа 55 яшьләр тирәсендәге хатын кирәк. Үзем күченеп китмим, минем яныма килеп тормыш итәрдәй хатын булсын. Хәзер бит хатыннар төрлечә була, үзегез беләсез. Авыл җирендә торасылары килми аларның хәзер, иркәләнеп беттеләр. Ә миңа әйбәт хатын кирәк, начар гадәтләре булмасын, авылда яшәрлек булсын. Ә авылда яшәгәч, эшләмичә генә торып булмый. Бакча да бар, йорт-җир дә бар. Бакчамда викторияләр күп, алмагачлар да үсә, бәрәңге бакчасы аерым. 3 сутыйда бәрәңге утыртам мин.



Авылыбыз зур безнең, ныклы мишәр авылы. Йорт-җирем дә әйбәт минем, аерым-аерым бүлмәләр дә бар, мунча да бар, машинам да бар. Мин еш кына шабашкага чыгып китәм. Менә шул чакта үзенә калган дөньяны карап, тәртипләп тора торган, үзе хуҗа да, хуҗабикә дә булып калырлык хатын кирәк миңа.

**НАЗЫЙМ.**
**Комсомольски муниципаль округы, Урмай авылы. 8-960-306-50-76.**

# СОҢГЫ ТАЛПЫНУ

***Исәнмесез, редакциядә эшләүчеләр! Мин сездән үтенеп сорыйм, зинһар, белдерү бастырып чыгарыгыз әле. Тормыш итәр өчен хатын кирәк миңа. Алдамый торган, чын ихластан бергә яшәргә дигән, 70-75 яшьләр тирәсендәге хатын булсын иде. Үземә 75 яшь, аякта йөреп торам, бакча эшләрен яратып башкарам, өйдә утырып торырга яратмыйм, телевизорны кич белән генә бераз карап алам.***

Газетага беренче генә белдерү бирүем түгел. “Язмыш кочагы”на танышу белдерүен бер-ике тапкыр язганым булды. Шалтыратучылар да булды, баргалап та кайттым. Бер-ике көн эшләтәләр дә: "Син миңа эшләргә генә кирәк идең, эшем бетте", – дип кайтарып җибәрәләр. Кайсылары “акча” дип кенә яшәде. Продуктлар алдым, үзең белеп тот дип, банкомат картасын да бирдем хәтта. Анысының малае эчә торган иде, икәүләшеп акча санадылар. Ә үзләре: “Син саран”, “Акчаны саныйсың”, – дип тынычлык бирмәделәр. Алдан әйбәт сыман булалар да, аннан гел гаеп эзлиләр, бүлше йортка ир-ат кертмим, үзем генә яшим дип куалар.

Ышанычлы, тәртипле хатын булсын иде дип телим. Булса, була, булмаса юк инде, бүтән белдерү бирәсем килми. Бусы – соңгы талпыну. Ничә ел эзләргә була инде хәзер, хатын үлгәнгә дә күпме булды бит... Аннан соң ничә кеше белән танышып карадым – барып чыкмый.

**Буадан булам.**
**Телефоным: 8-927-423-87-15, ватсап та шушы номерда.**

## Тормыш иптәше эзләүчеләр игътибарына!

*Танышырга, иптәш табарга ниятләгәнсез икән, без сезгә булдыра алган кадәр ярдәм итәргә тырышырбыз. Моның өчен хат язып салырга була. Яисә редакциягә шалтыратыгыз. Үзегез турында, ниндирәк кеше белән танышасыгыз килүе турында сөйләшербез.*

**Редакция телефоннары**:
8-937-771-76-08 (Алсу), 8-917-855-71-52 (Лилия).
**Ватсап шушы ук номерларда.**
**Хатлар өчен адрес:** 420100, Казан шәһәре, Сахаров ур., 27 йорт, а/я 175.
**Электрон адрес:** jasmina.gazeta@mail.ru

***Алларым аллар ата,***
***Гөлләрем гөлләр ата.***
***Сине уйлап ята-ята,***
***Айлар батып, Чулпан калка,***
***Сызылып таңнар ата.***

***Алларга ал сан икән,***
***Гөлләргә гөл сан икән.***
***Бу мәхәббәт дигән нәрсә***
***Бер шытып тамыр җибәрсә,***
***Тәмам исертә икән.***

**Татар халык җыры.**






## Бәрәңге бакчасын хрен басты

Бәрәңге бакчасын хрен басты. Ничек котылырга аннан, кем белә? Хәзер 2-3 ел көрәшәбез инде аның белән, көрәк белән тамырын казып-казып алабыз, быелтыр төрле агулар да сибеп карадык – булышмый! Хрен үсә, бәрәңге юк! Хренның тамырлары нык, бәрәңгене кысрыклый, тегесе үсә алмый. Бөтен бәрәңге бакчасын зур тизлек белән шушы хрен басып бара. Нишләргә?

**ЛАРИСА, Башкортостаннан.**

## Бетчә

15 яшьлек кызымның бите тулы бетчә. Үсмер чакта бөтен кызларда, малайларда бетчә була инде ул, анысын аңлыйм. Үзебезнең дә шулай булган иде. Әмма минем кызда гади бетчә генә түгел шул. Чуан сыман булып тора торган, фурункул сыман бик зур, чия кызыл төстә ул бетчәләр. Әллә ничә төрле лосьоннар да алабыз инде, иртәле-кичле юына торган төрле әйберләре дә бар, кремнары да бар. Берсе булышмагач, икенче төрлене, аннан соң өченче төрлене, аннан соң тагын башкасын алабыз. Миллион төрле крем алыштырдык инде хәзер, әмма берсе дә булышмый. “Ясминә” укучылары арасында шушы ук проблема белән яшәүче ата-аналар бардыр, алар нишлиләр икән, уртаклашсыннар иде. Белмим инде, әллә врачы бар микән соң аның? Алай дисәң, аның өчен шәһәргә, түләүле больницаларга барасы булыр инде, үзебездә аның ишене ишеткән юк.

**ЭЛЬМИРА.**

## Кеше каршында бигрәк уңайсыз

Миңа 45 яшь. Бер проблема бар: мин көн дәвамында какырып йөрим. Тын юлларыннан какрык (мокрота) килә. Урамга чыккач та, ирләр сыман төкеренеп йөрергә кирәк. Кеше каршында бигрәк уңайсыз. Ир әйтә, син озак еллар тәмәке тарткан ирләрдән дә болайрак какырынасың, ди. Ә мин бит тәмәке тартмыйм! Тын юлларын чистартырга кирәктер дип уйлыйм. Бәлки ниндидер үләннәр эчәргә кирәктер, пар суларга кирәктер. Шуларны белгән кеше юк микән? Бертуктаусыз җыелып торган какырыктан ничек арынырга була?

**Укучыгыз.**

## Дустым

Балачактан аралашып яшәгән дустым бар. Нәрсә булса да, булмаса да гел бергә без: атна саен диярлек очрашабыз, көн дә диярлек телефоннан сөйләшәбез. Борчу-шатлыклар да, көндәлек мәшәкатьләр дә уртак. Язмышлар да охшаш хәтта: икебездә дә икешәр кыз үсеп килә, икебез дә соңгы чиккә җиткәнче түзеп, ирләребез белән аерылыштык. Мин унбиш ел яшәдем, дустым унбер елдан соң аерылышты. Балалар зурлар диярлек инде. Аныкылар да, минекеләр дә чыгып киттеләр, укыйлар, аена бер-ике кайтып йөриләр. Менә шушы дустым соңгы бер-ике елда салгалый башлады. Эшендә әйбәт чутта йөри ул, бар да хөрмәт итә, бик тәртипле хатын, балаларын да әйбәт итеп үстерде. Әмма кайчан карама, кичләрен кулында бокал. Бакчасы да ялт иткән, өе дә тәртип. Тәртипне шулай “тамызыптамызып” эшли. Миңа да: "Әйдә, кил, кич утырабыз", – ди. “Кич утырабыз” дигәне дә шул – шешә белән. Һәр нәрсәнең үз урыны, үз нормасы була дип уйлыйм мин. Көн саенга китү әйбәткә алып бармый. Әмма дустым белән ул турыда сөйләшкәнем юк. Ул темага ничек сөйләшергә кирәген дә белмим, дөресен генә әйткәндә. Дус булса да, әллә дөрес аңлый, әллә юк. Әйтеп, үпкәләтеп, балачактан килгән дуслыкны да югалтасы килми. Минем аннан бер генә дә начарлык күргәнем юк. Авыр чакта – ул беренче булып ярдәм кулын суза, шатлыгымны да ул беренче булып уртаклаша. Минем ишеткәнем бар: имеш, хатын-кыз эчкечелеккә тиз бирешә, аларны дәвалап та булмый диләр. Белмим инде, бәлки юкка борчыламдыр. Ә бәлки юкка да түгелдер. Бәлки туктатып калыр өчен хәзердән чаң сугарга, дөрес итеп сөйләшергә кирәктер. Ә дөресе ничек була икән соң аның, кем белә?

**Зинһар, исемемне язмагыз.**

**Редакциядән.** Хөрмәтле укучыларыбыз! Укып, күреп торасыз – һәркемнең үз борчуы. Арабызда менә шушы сорауларга җавап белүчеләр бардыр бәлки. Ярдәм сораган кешеләргә әйтер сүзегез, бирер киңәшегез бар икән, шалтыратыгыз. Без һәр киңәшне теркәп, киләсе санда бастырып та чыгарабыз. Авыр тормышны бераз җиңеләйтеп, бер-беребез белән белгәннәрне уртаклашып, аралашып, ярдәмләшеп яшик.

podpiska.pochta.ru